ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.03.2022 с.Старое Дрожжаное №166

Авыл җирлекләренә карата генераль планнар әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән, алар чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне тулыландыру өлешендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына үзгәрешләр проектын әзерләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2022 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында» 18/2 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Городище, Звезда, Марс, Яңа Ишле, Үби, Иске Чокалы, Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлекләренә карата генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән, алар чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне тулыландыру өлешендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына үзгәрешләр проектын әзерләргә (алга таба-Карар).
2. Городище, Звезда, Марс, Яңа Ишле, Уби, Иске Чокалы, Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлекләренә карата Карар кабул ителгән, алар чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне тулыландыру өлешендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына үзгәрешләр проекты буенча чаралар планын, чараларны үтәү срокларын расларга (1 нче кушымта).
3. Городище, Звезда, Марс, Яңа Ишле, Уби, Иске Чокалы, Чуаш Чүпрәлесе

авыл җирлекләренә карата Карар кабул ителгән, алар чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне тулыландыру өлешендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына үзгәрешләр проектын әзерләү буенча эшләрне финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге https://drogganoye.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «29» 03
166 номерлы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр проектын әзерләү чаралары
планы

| № п/п | Чараның исеме | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 2 | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы ТПСна үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итү | 10 эш көне |
| 3 | Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан техник биремне раслау | 1 эш көне |
| 4 | Торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының ТПСна үзгәрешләр кертү эшләрен башкаруга килешү төзү | 5 эш көне |
| 5 | Чүпрәле муниципаль районы ТПС ның торак пунктлары чикләренең урнашу урыны тасвирламасын, картографик һәм текст материалларын әзерләү | 3 ай |
| 6 | Татарстан Республикасы буенча «Росреестрның ФКП» ФДБУндә торак пунктлар чикләре тасвирламалары | 7 эш көне |
| 7 | ТП ФГИСта МР ТПСына үзгәрешләр кертү һәм кертелгән материаллардан файдалануны тәэмин итү проектын урнаштыру | 1 эш көне |
| 8 | МР ТПСна үзгәрешләр проекты буенча килешү үткәрү һәм җыелма бәяләмә алу | 2 ай |
| 9 | МР ТПСна үзгәрешләр проектын раслау (Совет тарафыннан карар кабул итү) | Чүпрәле муниципаль районы Советының чираттагы сессиясендә |
| 10 | ЕГРНга торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертү | 15 эш көне |